**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь 2013 ел Казан шәһәре № 7-20/т

***ААҖ “Бегишево” Аэропорты” тарафыннан аэропортта хезмәт күрсәтү өчен тарифларның (җыемнарның) максималь чиген билгеләү***

“Табигый монополиялар турында” 17.08.1995 №147-ФЗ Федераль законы нигезендә, “Табигый монополиялар субъектлары тарафыннан транспорт терминалларында, портларда, аэропортлар һәм эчке су юлларының инфраструктурасын кулланудa хезмәт күрсәтү өчен бәяләрне (тарифлар, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу” 23.04.2008 №293 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, һәм “Россия Федерациясе субъектлары тарифларны дәүләти җайга салучы башкарма хакимият органнарының табигый монополиялар субъектлары эшчәнлеген тикшерүдә катнашуы турында” 10.12.2008 №950 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты 2010 елның 15 июнендә №468 карары тарафыннан расланган, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты кагыйдәнамәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. ААҖ “Бегишево” Аэропорты” өчен Россия Федерациясе җирендә теркәлгән юридик затларның һава судноларын карап тору, хезмәт күрсәтү өчен чик максималь аэропорт җыемнарын һәм тарифларын билгеләргә яисә Россия Федерациясе гражданнары, пассажирларны, йөкләр җибәрүче, кабул итүче, аэропорт сервислары белән кулланучыларны исәпкә алмыйча, шулай ук әлеге карарның 1 һәм 2нче кушымталары нигезендә чит ил эксплуатантларының һава судноларына хезмәт күрсәтү өчен.

2. “ААҖ “Бегишево” Аэропорты” тарафыннан аэропортта хезмәт күрсәтү өчен тарифларның (җыемнарның) максималь чиген билгеләү турында” 25.11.2011 №7-38/т Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты
карарының 1нче кушымтасы
11 декабрь 2013 ел № 7-20/т

## ААЖ "Бегишево" Аэропорты" өчен Россия Федерациясе җирендә теркәлгән юридик затларның һава судноларын карап тору, хезмәт күрсәтү өчен чик максималь аэропорт җыемнары һәм тарифлары, яисә Россия Федерациясе гражданнары, пассажирларны, йөкләр җибәрүче, кабул итүче, аэропорт сервислары белән кулланучыларны исәпкә алмыйча

| № п/п | Җыем яисә тариф исеме | Үлчәү берәмлеге | Җыем һәм тарифның зурлыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | Очып китү-очып төшү өчен җыем (аңа кертелә: очып төшкәннән соң пассажир суднолары өчен аэродромда 3 сәгать басып тору, йөк ташучы, йөк ташучы-пассажир сертификация үткән һава кораблары типлары өчен 6 сәгать, әгәр дә аларда килеп төшү аэропортында эшкәртелергә (төялергә һәм/яисә бушатылырга) тиешле йөкләр (мәс. почта) бар икән) | сум./т мвм | 546,0 |
| 2 | Очып китү-очып төшү өчен җыем (аңа кертелә: очып төшкәннән соң пассажир суднолары өчен аэродромда 3 сәгаттән күбрәк басып тору, йөк ташучы, йөк ташучы-пассажир сертификация үткән һава кораблары типлары өчен 6 сәгать, әгәр дә аларда килеп төшү аэропортында эшкәртелергә (төялергә һәм/яисә бушатылырга) тиешле йөкләр (мәс. почта) бар икән) | % җыемнан очып китү-очып төшү 1 сәгать өчен | 5,0 |
| 3 | Авиацион куркынычсызлык тәэмин итү өчен җыем алу | сум./т мвм | 303,0 |
| 4 | Аэровокзал комплексы белән куллану өчен җыем алу :<br>эчке линиядә<br>халыкара линиядә | сум./пасс. | <br>63,0<br>78,0 |
| 5 | Пассажирларга хезмәт күрсәтү тарифы:<br>эчке линиядә<br>халыкара линиядә | сум./пасс. | <br>153,0<br>210,0 |
| 6 | Авиацион ягулык саклау өчен тариф | сум./т | 2434,0 |
| 7 | Һава судноларга авиацион ягулык салу тарифы | сум./т | 1796,0 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештуры һәм җайга салу бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты
карарының 2нче кушымтасы
11 декабрь 2013 ел № 7-20/т

ААҖ "Бегишево" Аэропорты" белән кулланучылар – чит ил һава судноларының эксплуатантларына
хезмәт күрсәтү өчен чик максималь аэропорт җыемнары

| № п/п | Җыем исеме | Үлчәү берәмлеге | Җыем зурлыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | Очып китү-очып төшү өчен җыем (очып төшкәннән соң пассажир судноларының өчен аэродромда 3 сәгать басып тору исәпкә алына) | долл. АКШ/ т мвм | 17,6 |
| 2 | Стоянка өчен җыем (очып төшкәннән соң 3 сәгаттән артык басып тору очрагында) | % очып китү-очып төшү Бер тәүлек өчен | 15,0 |
| 3 | Авиацион куркынычсызлык тәэмин итү өчен җыем алу | долл. АКШ/ т мвм | 9,3 |
| 4 | Аэровокзал комплексын куллану өчен җыем | долл. США/ пасс. | 10,0 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
дәүләт комитеты,
Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештыру һәм җайга салу бүлеге